КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 14 октябрь г.Казань № 880

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 27 июль, 659 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлек-ләрендә коммерциягә карамаган бакча-чылык яки яшелчәчелек ширкәтләрен, шулай ук 2019 елның 1 гыйнварына кадәр гражданнар тарафыннан бакчачылык, яшелчәчелек яки дача хуҗалыгын алып бару өчен оештырылган коммерциягә карамаган оешмаларны тәэмин итә торган электр челтәре хуҗалыгы объектларын төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлау эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммерциягә карамаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтләрен, шулай ук 2019 елның 1 гыйнварына кадәр гражданнар тарафыннан бакчачылык, яшелчәчелек яки дача хуҗалыгын алып бару өчен оештырылган коммерциягә карамаган оешмаларны тәэмин итә торган электр челтәре хуҗалыгы объектларын төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлау эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 27 июль, 659 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 7 июль, 647 нче; 2022 ел, 30 декабрь, 1474 нче, 2023 ел, 19 май, 611 нче

карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммерциягә карамаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтләрен, шулай ук 2019 елның 1 гыйнварына кадәр гражданнар тарафыннан бакчачылык, яшелчәчелек яки дача хуҗалыгын алып бару өчен оештырылган коммерциягә карамаган оешмаларны тәэмин итә торган электр челтәре хуҗалыгы объектларын төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлау эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (карарга теркәлгән).

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 27 июль, 659 нчы карары белән расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 14 октябрь, 880 нче карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммерциягә карамаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтләрен, шулай ук 2019 елның 1 гыйнварына кадәр гражданнар тарафыннан бакчачылык, яшелчәчелек яки дача хуҗалыгын алып бару өчен оештырылган коммерциягә карамаган оешмаларны тәэмин итә торган электр челтәре хуҗалыгы объектларын төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлау эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга, гомуми таләпләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантларны, юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук күрсәтелгән субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар алучыларны товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә һәм сайлап алуны уздыруга физик затларга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары, Татарстан Республикасы  Бюджет кодексы нигезендә эшләнгән һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммерциягә карамаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтләрен, шулай ук 2019 елның 1 гыйнварына кадәр гражданнар тарафыннан бакчачылык, яшелчәчелек яки дача хуҗалыгын алып бару өчен оештырылган коммерциягә карамаган оешмаларны тәэмин итә торган электр челтәре хуҗалыгы объектларын төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлау эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү механизмын билгели (алга таба тиешенчә - субсидияләр, Эшләр, бакчачылык ширкәтләре).

1.2. Субсидия бирү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм бу Тәртипнең 1.1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен бюджет акчасын алучы буларак бюджет акчасы белән баш эш итүчегә – Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына (алга таба – вәкаләтле орган) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

1.3. Субсидияләр, Эшләр башкаруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында, оештыру-хокукый рәвешенә бәйсез рәвештә (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән тыш) юридик затларга бирелә.

1.4. Субсидия турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасы бердәм порталының (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

1.5. Вәкаләтле органның субсидия алучыны сайлап алуда катнашучылар белән (алга таба - сайлап алу) үзара хезмәттәшлеге документларны электрон рәвештә «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында (алга таба - «Электрон бюджет» системасы) файдаланып гамәлгә ашырыла.

1.6. «Электрон бюджет» системасыннан файдалану мөмкинлеге «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификация һәм аутентификация бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып гамәлгә ашырыла.

## II. Субсидия бирү шартлары һәм тәртибе

2.1. Сайлап алуда катнашу турында тәкъдимне (заявканы) карау датасына (алга таба - заявка) һәм субсидия бирү турында килешү төзү торышы буенча сайлауда катнашучыга туры килергә тиешле таләпләр:

сайлап алуда катнашучы чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмау. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статуслы) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

сайлап алуда катнашучы экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормау;

сайлап алуда катнашучы БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО

Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

сайлап алуда катнашучы бу Тәртипнең 1.1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмаска тиеш.

сайлап алуда катнашучы «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

сайлап алуда катнашучының бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү бурычы булмау яки Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пункты белән билгеләнгән күләмнән артмый;

сайлап алуда катнашучының башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычы булмау (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тиешле очраклардан тыш);

сайлап алуда катнашучы үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашкан юридик затка кушу, башка юридик затка кушу формасында үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмаска, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәскә, сайлап алуда катнашучы эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаска тиеш;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки сайлап алуда катнашучының баш бухгалтеры (булганда) турында мәгълүматлар булмау.

2.2. Сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 3.1 пункты нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү автомат рәвештә «Электрон бюджет» системасында сайлап алуны уздыруны тәэмин итә торган дәүләт мәгълүмат системалары (алга таба - дәүләт мәгълүмат системалары) белешмәләре нигезендә, шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып, гамәлгә ашырыла.

2.3. «Электрон бюджет» системасында автомат тикшерүне гамәлгә ашыруның техник мөмкинлеге булмаган очракта сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау сайлауда катнашучы тарафыннан «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәү турында тамгаларны электрон рәвештә язып кую юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.4. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек кысаларында Вәкаләтле органның файдалану мөмкинлеге булган дәүләт мәгълүмат системаларында тиешле мәгълүмат булган очракта Вәкаләтле орган сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган документларны тапшыруны таләп итәргә хокуклы түгел, сайлап алуда катнашучы күрсәтелгән

документларны һәм мәгълүматны үз инициативасы белән Вәкаләтле органга тапшырырга әзер булган очрактан тыш.

2.5. Субсидия бирү шарты булып әлеге Тәртипнең 3.4 пунктында күрсәтелгән сайлап алу критерийларына сайлап алуда катнашучының туры килүе тора.

2.6. Финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган электр челтәре хуҗалыгы объектларын төзү һәм реконструкцияләү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнар юнәлешләре түбәндәгеләр:

проект-тикшеренү эшләре;

инженер-геодезия төшерүләре;

эшләргә дәүләт экспертизасы, шул исәптән сметаларның дөреслеген тикшерү;

төзелеш-монтаж эшләре, шул исәптән тиешле (кирәкле) җиһазлар сатып алу;

төзелеш контролен гамәлгә ашыру эшләре;

эшләтеп җибәрү эшләре;

башкарма төшерүне үтәү.

2.7. Финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган электр челтәре хуҗалыгы объектларын ремонтлау эшләрен башкаруга бәйле чыгымнар юнәлешләре түбәндәгеләр:

эшләргә дәүләт экспертизасы, шул исәптән сметаларның дөреслеген тикшерү;

төзелеш-монтаж эшләре;

эшләтеп җибәрү эшләре.

2.8. Субсидия күләме (S) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S = P_1 + P_2 + P_3 + ... + P_n,$$

монда:

$P_1, P_2, P_3, ..., P_n$ – әлеге Тәртипнең 2.6, 2.7 пунктларында күрсәтелгән юнәлешләр буенча чыгымнар, алар, һәр бакчачылык ширкәте буенча Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының «Электр челтәре хуҗалыгы объектлары өлешендә электр энергетикасы объектларын капиталь төзүнең типовой технологик карарлары бәясенең якынча нормативларын раслау турында» 2024 елның 26 февралендәге 131 номерлы боерыгы нигезендә Эшләр башкаруга җыелма исәп белән (алга таба - җыелма исәп) каралган.

2.9. Субсидия алучыны сайлап алу процедурасы тәкъдимнәр соратып алу юлы белән үткәрелә. Сайлап алу, сайлап алуда катнашучының сайлап алу критерийларына һәм заявкалар керү чиратына туры килүеннән чыгып, сайлап алуда катнашучы өчен сайлап алуда катнашучылар тарафыннан җибәрелгән заявкалар нигезендә үткәрелә. Сайлап алу «Электрон бюджет» системасында гамәлгә ашырыла.

2.10. Субсидия Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә кредит оешмаларында субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, бер тапкыр, исәп-хисап яки корреспондент счетына күчерелә.

2.11. Субсидия бирү нәтиҗәсе - бакчачылык ширкәтләренең саны, аларда эшләр агымдагы финанс елның 31 декабренә кадәр тәмамланды.

## III. Сайлап алуны үткәрү тәртибе

3.1. Вәкаләтле орган сайлап алуны уздыру турында карар кабул ителгән көннән соң өч көн эчендә бердәм порталда һәм үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (https://mpt.tatarstan.ru/) вәкаләтле орган җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имза салынганнан соң сайлап алу үткәрелүе турында игълан һәм субсидия турындагы мәгълүматның бердәм порталында бастырып чыгарылганнан соң гына урнаштыра.

3.2. Сайлап алуны уздыру турында игълан «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә формалаша, вәкаләтле орган җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән зат) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, бердәм порталда бастырыла.

3.3. Сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

сайлап алуны үткәрү сроклары;

заявкаларны бирә башлау һәм кабул итү тәмамлану даталары. Заявкалар кабул итүне тәмамлау датасы сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 календарь көннән иртәрәк була алмый;

вәкаләтле органның исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

әлеге Тәртипнең 2.11 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсе (нәтиҗәләре);

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге дәүләт мәгълүмат системасының домен исеме һәм (яисә) битләре күрсәткечләре;

әлеге Нигезләмәнең 2.1 пункты һәм сайлап алуда катнашучылар тарафыннан аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеге нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләр;

әлеге Тәртипнең 3.4 пункты нигезендә сайлап алу критерийлары;

заявкалар бирү тәртибе һәм әлеге Тәртипнең 3.5 – 3.11 пунктлары нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр;

әлеге Тәртипнең 3.8 пункты нигезендә заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

әлеге Тәртипнең 3.12 – 3.21 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләре;

эшләп бетерү өчен заявкаларны кире кайтару тәртибе;

заявкаларны кире кагу тәртибе, шулай ук әлеге Тәртипнең 3.15 пункты нигезендә аларны кире кагу нигезләре турында мәгълүмат;

сайлап алу кысаларында бүленә торган субсидия күләме, әлеге Тәртиптә билгеләнгән субсидия күләмен исәпләү тәртибе, сайлап алу нәтиҗәләре буенча субсидияне бүлү кагыйдәләре, шулай ук сайлап алуда җиңүчеләрнең иң чик саны;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләренә аңлатма бирү тәртибе, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасы;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) имза кую вакыты;

субсидия бирү турында килешү төзүдән читләшкән сайлап алу җиңүчеләрен тану шартлары;

сайлап алу йомгаклары беркетмәсен (сайлап алуны уздыру йомгаклары турындагы документны) бердәм порталда урнаштыру сроклары, алар сайлап алу җиңүчесен билгеләгән көннең иртәгесеннән соңгы 14 календарь көннән дә соң була алмый.

3.4. Сайлап алуда катнашучылар түбәндәге сайлап алу критерийларына заявка бирелгән датага карата туры килергә тиеш:

0,4 – 10 кВ электр хуҗалыклары объектларын төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау чараларын гамәлгә ашыру буенча инвестиция проектларын гамәлгә ашыру тәҗрибәсе булу, кимендә 3 ел;

«Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру һәм Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түләү;

сайлап алуны игълан итүгә кадәр өч елдан да соңга калмыйча юридик зат буларак теркәү;

сайлап алуда катнашучының штатында 0,4 – 10 кВ электр хуҗалыклары объектларында ремонт һәм реконструкция эшләрен оештыруга, күзәтүгә һәм контрольдә тотуга җаваплы даими персонал булу;

эшләр башкарырга планлаштырыла торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә җитештерү участоклары, җитештерү, оператив, оператив-ремонт персоналы, махсус техника булу.

3.5. Сайлап алуда катнашучы сайлап алуны уздыру турында игъланда күрсәтелгән срокларда заявканы «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә төзи һәм бирә һәм «Электрон бюджет» системасына документларның электрон күчермәләрен (сканлаштыру юлы белән электрон формага үзгәртелгән кәгазь чыганактагы документларны) тапшыра, аларны бирү сайлап алу үткәрү турында игъланда каралган.

«Электрон бюджет» системасында сайлауда катнашучы тарафыннан формалаштырылган заявка сайлап алуда катнашучы яисә ул вәкаләт биргән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланырга тиеш.

Сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявка бирү датасы булып, заявкага «Электрон бюджет» системасында теркәлү номеры бирелеп, аңа сайлап алуда катнашучы тарафыннан имза салынган көн санала.

Сайлап алуда катнашучы сайлап алуда катнашу өчен түбәндәге документларны үз эченә алган заявканы «Электрон бюджет» системасында урнаштыра:

вәкаләтле орган раслаган форма буенча субсидия бирү турында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлауда катнашучы турында, сайлауга бәйле рәвештә гариза, башка мәгълүматны сайлауда катнашучы турында мәгълүматны бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалык биргән сайлап алуда катнашучы җитәкчесе тарафыннан имзаланган гариза; Субсидия бирү турында гаризаның үзендә шул исәптән сайлауда катнашучы тәкъдим иткән субсидия бирү нәтиҗәсенең һәм соратып алына торган субсидия күләменең мәгънәсе булырга тиеш;

гамәлгә кую документларының күчермәләре;

сайлап алуда катнашучының җитәкчесе вәкаләтләрен раслый торган документлар күчермәләре;

җыелма исәп;

сайлап алуда катнашучының җитәкчесе тарафыннан имзаланган 0,4 – 10 кВ электр хуҗалыклары объектларын төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау чараларын гамәлгә ашыру буенча инвестиция проектларын гамәлгә ашыру тәҗрибәсе турында белешмә кәгазе;

сайлап алуда катнашучының җитәкчесе тарафыннан имзаланган сайлап алуда катнашучының штатында 0,4 – 10 кВ электр хуҗалыклары объектларында ремонт һәм реконструкция эшләрен оештыруга, күзәтүгә һәм контрольдә тотуга җаваплы даими персонал булу турында белешмә кәгазе;

сайлап алуда катнашучының җитәкчесе тарафыннан имзаланган эшләр башкарырга планлаштырыла торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә җитештерү участоклары, җитештерү, оператив, оператив-ремонт персоналы, махсус техника булу турында белешмә кәгазе;

сайлауда катнашучының әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә һәм әлеге Тәртипнең 3.4 пунктында билгеләнгән сайлап алу критерийларына туры килүе турында сайлап алуда катнашучы җитәкчесе кул куйган белешмә (ирекле формада).

3.6. Заявкага кертелә торган документларның һәм материалларның электрон күчермәләре барлык документны йә аның өлешен карау мәгълүматны карауны һәркем файдалана алырлык программа белән тәэмин итү чаралары белән карау мөмкинлеген тәэмин итә торган киң таралган ачык форматларга ия булырга тиеш һәм махсус программа яисә технологик чаралардан башка аларның эчтәлеге белән танышуны гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирми торган чаралар белән шифрланган яисә якланган булырга тиеш түгел.

3.7. Заявкада булган мәгълүматның һәм документларның тулылыгы һәм дөреслеге өчен, шулай ук аларны вакытында тапшыру өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә сайлап алуда катнашучы җаваплы була.

3.8. Сайлап алуда катнашучы заявканы сайлап алу тәмамланганга кадәр теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы. Сайлап алуда катнашучы, кирәк булганда, заявкалар бирү өчен билгеләнгән срок эчендә заявканы кабат бирергә хокуклы, шул ук вакытта заявка, “Электрон бюджет” системасында теркәлү номеры бирелеп, чират тәртибендә кергән көндә теркәүгә алына.»;

Сайлап алуда катнашучы заявканы үзгәртергә хокуклы:

сайлап алуда катнашучы электрон формада формалаштырылган заявкаларны кире алу турында хәбәрнамәдән һәм алга таба яңа заявка төзелгәннән соң заявкаларны кабул итү срогы тәмамланган көнгә кадәр;

заявканы карау этабында заявкаларны карау буенча комиссия (алга таба - комиссия) карары буенча гаризаны кире кайтару турында.

Заявкага үзгәрешләр кертү яисә заявканы кире алудан соң заявканы кабат бирү әлеге Тәртипнең 3.5 – 3.11 пунктларында күрсәтелгән сайлап алуда катнашучының заявкасын формалаштыруның шундый ук тәртибендә сайлап алуда катнашучы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3.9. Сайлап алу барышында сайлап алуда катнашучы бер заявка бирә ала.

Заявка керү көнендә чират тәртибендә «Электрон бюджет» системасында теркәү номерын бирү белән теркәлә.

3.10. Бердәм порталда сайлау үткәрү турында игълан урнаштырылган көннән башлап, сайлауның теләсә кайсы катнашучысы, сайлау тәмамланган көнгә кадәр өченче эш көненнән дә соңга калмыйча «Электрон бюджет» системасында тиешле гарызнамә төзү юлы белән сайлап алуны үткәрү турында игълан итү нигезләмәләрен аңлату турында Вәкаләтле органга иң күбе өч гарызнамә җибәрергә хокуклы. Мондый чакта вәкаләтле орган, әгәр күрсәтелгән гарызнамә заявкаларны кабул итү срогы тәмамланганчы өч эш көненнән дә соңга калмыйча кергән булса, мондый аңлатуны гамәлгә ашырмаска хокуклы.

3.11. Вәкаләтле орган әлеге Тәртипнең 3.10 пунктында күрсәтелгән гарызнамәгә җавап итеп, «Электрон бюджет» системасында аңлатмалар соратып алу көненнән соң ике эш көненнән дә соңга калмыйча, әмма заявкалар бирү тәмамланган көнгә кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча тиешле аңлатманы «Электрон бюджет» системасында булдыру юлы белән сайлап алуны уздыру турындагы игълан нигезләмәләренә аңлатма җибәрә. Вәкаләтле орган тарафыннан сайлап алуны уздыру турында игълан итү нигезләмәләрен аңлату күрсәтелгән белдерүдә булган мәгълүматның асылын үзгәртергә тиеш түгел.

«Электрон бюджет» системасында формалаша торган аңлатмадан файдалану әлеге пунктның беренче абзацы нигезендә сайлап алуның барлык катнашучыларына бирелә.

3.12. Заявкаларны карау өчен вәкаләтле орган хезмәткәрләре арасыннан комиссия төзелә. Комиссияне төзү тәртибе һәм комиссия турында нигезләмә вәкаләтле орган боерыгы белән раслана.

Заявкаларны карау түбәндәге предметка гамәлгә ашырыла:

сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килү;

әлеге Тәртипнең 3.4 пункты белән билгеләнгән сайлап алу критериеләренә туры килү;

документларның булуы һәм аларның әлеге Тәртипнең 3.6 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүе.

Вәкаләтле органга, шулай ук комиссиягә «Электрон бюджет» системасында аларны карау өчен заявкаларга керү, сайлап алуны үткәрү турында игълан итүдә билгеләнгән заявкалар бирү срогы тәмамланган көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча, ачыла.

«Электрон бюджет» системасында вәкаләтле орган тарафыннан заявкалар бирү срогы тәмамланганчы бер дата билгеләнергә мөмкин, шуннан соң комиссиягә «Электрон бюджет» системасында бирелгән заявкаларга керү ачыла.

Заявкаларны карау «Электрон бюджет» системасында комиссия тарафыннан заявкаларны карау өчен аларга комиссиягә керү мөмкинлеге ачылган көннән соң 10 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

3.13. Комиссия сайлап алуны уздыру турында игъланда билгеләнгән заявкаларны ачу көненнән соң килгән бер эш көненнән дә соңга калмыйча заявкаларны ачу беркетмәсен имзалый, алар сайлауда катнашу өчен килгән заявкалар турында түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

заявканы теркәү номеры;

заявка керү датасы һәм вакыты;

сайлап алуда катнашучының тулы исеме;

юридик затның адресы;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан соратып алына торган субсидия күләме.

Заявкаларны ачу беркетмәсе бердәм порталда автомат рәвештә төзелә һәм «Электрон бюджет» системасында комиссия әгъзаларының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук аңа кул куйган көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча бердәм порталда урнаштырыла.

3.14. Әгәр ул сайлап алуны уздыру турында игъланда күрсәтелгән таләпләргә туры килсә һәм заявканы кире кагу өчен нигезләр булмаса, заявка дөрес дип таныла.

Заявканың сайлап алуны уздыру турында игъланда күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турындагы карарлар заявка составында тапшырылган мәгълүматны һәм документларны сайлап алу нәтиҗәләрен тикшерү көненә комиссия тарафыннан кабул ителә.

3.15. Заявканы карау стадиясендә заявканы кире кагу өчен нигезләр түбәндәгеләр тора:

сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуны үткәрү турында игъланда күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

сайлап алуда катнашучы биргән заявканың һәм (яки) документларның сайлап алу турындагы белдерүдә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

әлеге Тәртип тарафыннан билгеләнгән таләпләргә, шул исәптән юридик затның урнашкан урыны һәм адресы турындагы мәгълүматның туры килүен раслау максатларында сайлап алуда катнашучы тәкъдим иткән документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявканың аны бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң бирелүе;

3.16. Заявкаларны карау нәтиҗәләре буенча, заявкаларны карау срогы тәмамланганнан соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча, комиссия тарафыннан заявкаларны карау беркетмәсе әзерләнә, ул кергән һәм каралган заявкаларның саны турында мәгълүматны, шулай ук сайлап алуның һәр катнашучысы буенча аның заявкасын тиешле дип тану яисә, кире кагу өчен нигезләр күрсәтелеп, аның заявасын кире кагу турында мәгълүматны үз эченә ала.

Заявкаларны карау беркетмәсе заявкаларны карау нәтиҗәләре нигезендә бердәм порталда автомат рәвештә төзелә һәм «Электрон бюджет» системасында комиссия әгъзаларының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук аңа кул куйган көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча бердәм порталда урнаштырыла.

3.17. Гаризаны тулы, һәрьяклап һәм объектив карау максатларында үзләре тапшырган документлар һәм мәгълүмат буенча аңлатмалар алу өчен сайлап алуда катнашучыдан мәгълүмат һәм документлар алырга кирәк булган очракта вәкаләтле орган «Электрон бюджет» системасыннан файдаланып, документлар һәм мәгълүматка карата аңлатуны сайлап алуда катнашучыдан соратып ала, кирәк булса, сайлауда барлык катнашучыларга бертигез дәрәҗәдә җибәрелә.

Әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән гарызнамәдә вәкаләтле орган тиешле гарызнамә урнаштырылган көннән соң кимендә ике эш көне булырга тиешле документларны һәм мәгълүматны сайлап алуда катнашучының аңлатма бирү срогын билгели.

Сайлап алуда катнашучы «Электрон бюджет» системасына әлеге пунктның беренче абзацы нигезендә соратып алына торган мәгълүматны һәм документларны, әлеге пунктның икенче абзацы нигезләмәләрен исәпкә алып, тиешле гарызнамә белән билгеләнгән срокларда төзи һәм тапшыра.

Сайлап алуда катнашучы әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән сорауга җавап биргән очракта, әлеге пунктның икенче абзацы нигезләмәләрен исәпкә алып, соратып алына торган документлар һәм тиешле гарызнамә белән билгеләнгән вакытта мәгълүмат тапшырмаган булса, бу хакта мәгълүмат сайлап алу йомгакларын ясау беркетмәсенә кертелә.

3.18. Аларны карау нәтиҗәләре буенча тиешле дип танылган гаризаларны ранжировкалау заявкалар керү чиратыннан чыгып комиссия тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3.19. Сайлап алуда җиңүче булып сайлап алуны уздыру турында игълан итүдә күрсәтелгән бүлеп бирелә торган субсидия күләме чикләрендә кергән заявкаларны ранжировкалау нәтиҗәләре буенча комиссия тарафыннан төзелгән рейтингка кертелгән сайлап алуда катнашучы танылa.

3.20.Сайлап алуны тәгәлләү һәм җиңүчене ачыклау максатларында сайлап алу йомгакларын ясау беркетмәсе төзелә, түбәндәге мәгълүматларны үз эченә ала:

заявкаларны карап тикшерүне үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

заявкалары кабул ителмәгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен, шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килми торган нигезләмәләрен күрсәтеп);

субсидия бирү турында килешү төзелә торган субсидия алучының исеме һәм аңа бирелә торган субсидиянең күләме.

Сайлап алу нәтиҗәләрен чыгару беркетмәсе сайлап алу җиңүчесен билгеләү нәтиҗәләре нигезендә бердәм порталда автомат рәвештә төзелә һәм «Электрон бюджет» системасында комиссия әгъзаларының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук аңа кул куйган көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча бердәм порталда урнаштырыла.

3.21. Беркетмә басылып чыкканнан соң биш эш көне эчендә вәкаләтле орган тарафыннан сайлап алу нәтиҗәләрен чыгарганнан соң, субсидия бирү турында йә вәкаләтле орган (яисә ул вәкаләт биргән зат) җитәкчесе тарафыннан раслана торган субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул ителә.

Субсидия алучыга субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның бу Тәртипнең 3.6 нчы пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмау факты билгеләнүе.

3.22. Сайлау түбәндәге очракларда булмаган дип танылa:

заявкалар бирү срогы тәмамланган көнгә бер генә заявка да бирелмәгән;

заявкаларны карау нәтиҗәләре буенча барлык заявкалар кабул ителмәгән.

Сайлап алу узмаган дип танылган, шулай ук сайлап алуны уздырганда әлеге Тәртипнең 1.1 пунктында билгеләнгән субсидияләр бирү максатларында вәкаләтле органга җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары бетерелмәгән очракта, вәкаләтле орган сайлап алуны уздыру турында игъланны кабат урнаштырырга хокуклы.

3.23. Бердәм порталда сайлап алуны үткәрүне гамәлдән чыгару турында Вәкаләтле орган тарафыннан игълан урнаштыру конкурста катнашучыларның заявкаларын бирү срогы тәмамланганчы бер эш көненнән дә соңга калмыйча рөхсәт ителә.

Сайлап алуны гамәлдән чыгару турында игълан электрон рәвештә “Электрон бюджет” системасының веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән төзелә, Вәкаләтле орган җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, бердәм порталда урнаштырыла һәм сайлап алуны гамәлдән чыгару сәбәпләре турында мәгълүмат туплана.

Сайлап алуны үткәрүне гамәлдән чыгару очрагы булып әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен вәкаләтле органга җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары кире алу тора.

Заявкалар биргән сайлап алуда катнашучылар «Электрон бюджет» системасында сайлап алуны үткәрүне юкка чыгару турында мәгълүмат бирәләр.

Сайлап алу бердәм порталда аны уздырмау турында белдерү урнаштырылган көннән сайлап алу гамәлдән чыгарылган дип санала.

Сайлап алуны юкка чыгару срогы тәмамланганнан соң, әлеге пункт нигезендә һәм конкурста җиңүче белән субсидия бирү турында килешү төзегәнче вәкаләтле орган сайлауларны җиңеп булмый торган көч шартлары барлыкка килгән очракта гына юкка чыгарырга мөмкин.

## IV. Субсидия бирү турында килешү төзү тәртибе

4.1. Субсидия бирү Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә төзелә торган субсидия бирү турындагы килешү нигезендә гамәлгә ашырыла. Субсидия бирү турында килешү «Электрон бюджет» системасында төзелә.

Субсидия бирү турында килешү вәкаләтле органга субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган тугыз көн эчендә төзелә. Кирәк булганда субсидия бирү турындагы килешүгә өстәмә килешү төзү кирәклеге турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә субсидия бирү турында килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзелә.

Субсидия алучы, шулай ук субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акчалар алучы башка юридик затлар тарафыннан субсидия исәбенә алынган чит ил валютасы акчалары исәбеннән, югары технологияле импорт җиһазларын, чималны һәм комплектлаучы әйберләрне сатып алганда (китергәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш, акчалар алуны тыю.

4.2. Субсидияләр бирү турындагы килешүдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнар юнәлешләре;

субсидия алучы, шулай ук субсидияләр алучылар белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы башка юридик затлар тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан алынган акча исәбеннән чит ил валютасы (югары технологияле импорт җиһазын, чимал һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш) сатып алу тыела.

субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) аларга карата вәкаләтле орган тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерүгә субсидия алучының ризалыгы;

субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә алынган субсидияләрне һәм чараларны Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару тәртибе һәм сроклары;

бу Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән, элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары вәкаләтле органга киметелгән очракта, субсидия бирү турындагы килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар белән килешеп булмаганда субсидия бирү турындагы килешүне өзү хакында, субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән күләмдә бирү мөмкин булмавына китерә торган шарт.

4.3. Кушылу, кушу яисә үзгәртеп оештыру рәвешендә субсидия алучы үзгәртеп оештырылганда, субсидия бирү турында килешүгә йөкләмәдә зат алышыну өлешендә субсидия бирү турында килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәреш кертелә, субсидия бирү турында килешүдә хокук варисы булып торган юридик зат күрсәтелә.

Субсидия алучыны бүлү, аерып бирү рәвешендә үзгәртеп оештырганда, шулай ук субсидия алучы бетерелгәндә субсидия бирү турында килешү, берьяклы тәртиптә субсидия бирү турында килешүне өзү турында хәбәрнамә булдырып һәм, субсидия алучы тарафыннан үтәлмәгән, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган йөкләмәләр һәм субсидиянең файдаланылмый калган өлешен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару турында мәгълүматны чагылдырып, субсидия бирү турында килешү буенча йөкләмәләрне үтәү турында акт төзеп өзелә.»;

4.4. Субсидия алучы, сайлап алуда җиңүче “Электрон бюджет” системасына имза салуга субсидия бирү турында килешү кабул ителгән көннән алып эш көннәре санын сайлап алу турында килешүгә кул куймаган очракта, субсидия бирү турындагы килешүне имзалаудан читләшкән дип танылa һәм субсидия бирү турында килешү проекты буенча каршылыклар җибәрмәгән.

Субсидия бирү турында карарны юкка чыгару вәкаләтле орган карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.5. Вәкаләтле орган сайлауда җиңүченең сайлап алуны үткәрү турында игъланда күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве факты ачыкланган очракта яисә сайлауда җиңүче тарафыннан дөрес булмаган мәгълүмат тәкъдим ителгән очракта сайлап алуда җиңүче белән субсидия бирү турында килешү төзүдән баш тарта ала.

4.6. Вәкаләтле орган әлеге Тәртипнең 4.5 пунктында каралган нигезләрдә сайлап алуда җиңүче белән субсидия бирү турында килешү төзүдән баш тарткан очракта, субсидия бирү турында килешү төзүдән баш тарткан очракта, сайлап алуны үткәрү турында игълан белән билгеләнгән срокта субсидия бирү турында килешүне сайлауда җиңүче тарафыннан сайлап алу турында килешү төзелмәү язмаган очракта, вәкаләтле орган заявкасы гаризаны югалту тәртибендә һәм җиңүче дип танылган соңгы катнашучыга сайлап алуда катнашучы белән субсидия бирү турында килешү төзи.

## V. Хисаплылыкка карата таләп

5.1. Субсидия алучы, хисап чорыннан соң килә торган квартал саен, 30 көннән дә соңга калмыйча, «Электрон бюджет» системасында вәкаләтле органга Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән субсидия бирү турында килешүнең типовой рәвешенә кушып бирелә торган рәвешләр буенча тапшыра:

субсидия бирү нәтиҗәләре мәгънәсенә ирешү турында хисап;

субсидия финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап, һәр бакча ширкәте буенча чыгымнар турында мәгълүмат белән.

5.2. Вәкаләтле орган әлеге Тәртипнең 5.1 пункты нигезендә субсидия алучы тарафыннан тапшырылган хисаплылыкны субсидия алучы аны «Электрон бюджет» системасында юллаган вакыттан алып 20 эш көне дәвамында тикшерә.

## VI. Субсидияләр бирү шартларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыруга таләпләр һәм аларны бозган өчен җаваплылык

6.1. Вәкаләтле орган субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра, дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

Вәкаләтле орган субсидия бирү турында килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләренә ирешүне һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгаларны (контроль нокта)

мониторинглауны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган нәтиҗәләргә ирешүне мониторинглау тәртибендә каралган тәртиптә һәм формалар буенча уздыра.

6.2. Субсидия, субсидия алучы тарафыннан субсидия бирелгәндә, шул исәптән вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс контроле органы үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган субсидияне тапшырганда билгеләнгән шартларны бозган очракта, субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсе турында, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру хакында хисаплар бирмәү турында вәкаләтле органның тиешле таләпләрен алган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына субсидия алучы тарафыннан кире кайтарылырга тиеш.

Субсидия алучы тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган, шул исәптән вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс контроле органы үткәргән тикшерүләр фактлары буенча аларның бозылуы ачыкланган һәм субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү турында, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисаплар тапшырылмаган очракларда, тулы күләмдә кире кайтарылырга тиеш.

Әгәр субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү турында килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешелмәгән булса, субсидия алучы субсидияне түбәндәге формула буенча билгеләнә торган күләмдә ($V_{\text{кире кайтару}}$) кире кайтаруны гамәлгә ашыра:

$$V_{\text{кайтару}} = (V_{\text{субсидия}} \times k),$$

монда:

$V_{\text{субсидия}}$ – хисап финанс елында субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү максатларында субсидия алучыга фактта бирелгән субсидия күләме;

k – субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешелмәү дәрәҗәсен чагылдыра, түбәндәге формула буенча билгеләнә торган коэффициент:

$$k = 1 - \frac{T}{S},$$

монда:

T – хисап датасына субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәсенең фактта ирешелгән күрсәткече;

S – субсидия алучы өчен субсидия бирү турында килешүдә килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең план буенча күрсәткече.

Субсидия акчасын кире кайтару күләме исәпләп чыгарылганда коэффициентның бары субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешелмәү дәрәҗәсе чагылдырыла торган уңай мәгънәләре кулланыла.

6.3. Субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмаган өлеше субсидия бирү елыннан соң килүче елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кайтарылырга тиеш.

6.4. Субсидия алучы тарафыннан субсидияләрне кире кайтару срогы бозылганда, вәкаләтле орган эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә күрсәтелгән акчаларны Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына түләтү чараларын күрә.

Әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджеты керемենә ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тартылган очракта, алар Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

6.5. Субсидия биргәндә билгеләнгән шартларның үтәлүе өчен тапшырыла торган документларның һәм белешмәләрнең дөреслеге өчен субсидия алучы җаваплы була.

6.6. Субсидия акчасын нәтиҗәле файдалануны тикшерүдә тоту вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

---